ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

6 август 2021ел № 5220

Муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан эре һәм башка килешүләр һәм аларны гамәлгә ашыруга кызыксыну булган килешүләр төзүне килештерү тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан эре һәм башка килешүләр һәм аларны гамәлгә ашыруга кызыксыну булган килешүләр төзүне килештерү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 6 августындагы
5220 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль унитар предприятиеләр,
муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан
эре һәм башка килешүләр һәм аларны гамәлгә ашыруга
кызыксыну булган килешүләр төзүне килештерү
тәртибе

1. Әлеге тәртип «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнде һәм гамәлгә куючылар (милекчеләр) тарафыннан хупланганнан соң гамәлгә ашырыла торган килешүләрне муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан килештерү тәртибен җайга сала, атап әйткәндә:

1) заемнар, йөкләмәләр, банк гарантияләрен алу, башка чикләүләр, таләпләрне киметү, бурычларны күчерү, шулай ук гади ширкәт шартнамәләре төзү белән бәйле килешүләр төзү;

2) муниципаль казна предприятиесенең төрләре һәм (яки) күләме казна предприятиесе уставында каралган башка килешүләрен төзү;

3) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе җитәкчесенең кызыксынуы булган килешүләр төзү;

4) эре килешү төзү.

2. Әлеге тәртип муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан үзләштерүләрне гамәлгә ашыруны килештерүгә кагылмый.

3. Муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан әлеге тәртипнең 1 пунктында каралган килешүләр төзүгә гамәлгә куючының ризалыгы яки баш тартуы Башкарма комитет карары формасында чагылдырыла.

4. Башкарма комитетның тармак органы тәэмин итә:

1) муниципаль унитар предприятиеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә әлеге тәртипнең 1 пунктында каралган килешүләр төзүне килештерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне;

2) әлеге тәртипнең 1 пунктында каралган килешүләр буенча йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тотуны;

3) муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна предприятиеләре тарафыннан эшчәнлекнең икътисадый нәтиҗәлелек

күрсәткечләре үтәлешен анализлау һәм унитар предприятиенең, казна предприятиесенең хисапларын һәм бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын карап тикшерү йомгаклары буенча, Россия Федерациясенең граждан законнарында каралган ысуллар белән үз вакытында муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль казна предприятиеләренең хокукларын яклау буенча чаралар күрүне.

5. Әлеге тәртипнең 1 пунктында каралган килешүләрне төзү максатында, муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе андый килешү төзүнең төп шартларын (яклары, предметы, бәясе, кабул ителгән йөкләмәләрнең гамәлдә булу срогы һәм үтәү тәртибе) күрсәтеп, хисап чорына (ел, агымдагы елның 6 ае, агымдагы ел кварталы) факттагы һәм пландагы икътисадый күрсәткечләрне теркәп, тиешле мөрәҗәгатьне (алга таба – мөрәҗәгать) Башкарма комитет Җитәкчесе адресына җибәрә.

6. Башкарма комитет Җитәкчесе, әлеге тәртипнең 5 пунктында каралган мөрәҗәгатьне, карап тикшерү өчен, бер эш көне эчендә Башкарма комитетның тиешле муниципаль унитар предприятиегә, муниципаль казна предприятиесенә кураторлык итә торган тармак органына (алга таба – Башкарма комитетның тармак органы) җибәрә.

7. Башкарма комитетның тармак органы муниципаль унитар предприятиенең, муниципаль казна предприятиесенең мөрәҗәгатен карап тикшерүне ун эш көне эчендә гамәлгә ашыра.

8. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитетның тармак органы түбәндәгеләрне әзерли:

1) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан килешүне гамәлгә ашыруны килештерү турында Башкарма комитет карары проектын (алга таба – килешүне килештерү турында карар проекты);

2) әлеге тәртипнең 9 пунктында каралган нигезләр буенча, килешү төзүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын.

9. Килешүне килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

1) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашыру планлаштырылган килешү шартлары гамәлдәге закон нормаларына һәм муниципаль хокукый актларга каршы килә;

2) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашыру планлаштырылган килешү шартлары муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан элек төзелгән шартнамәләр буенча кабул ителгән йөкләмәләрне бозуга шартлар тудыра;

3) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашыру планлаштырылган килешү шартлары аның бөлгенлеккә төшүенә (банкротлыкка) шартлар тудыра;

4) муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашыру планлаштырылган килешү шартлары унитар предприятиенең, казна предприятиесенең хисаплары һәм бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күрсәткечләреннән чыгып, икътисадый нигезләнмәгән.

10.Башкарма комитетның тармак органы җибәрә:

1) килешүне гамәлгә ашырудан баш тарту турында белдерү кәгазе проектын, имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә;

2) килешүне килештерү турында карар проектын, аны өч эш көне эчендә карап тикшерү өчен Башкарма комитетның финанс идарәсенә.

11. Килешүне килештерү турында карар проекты Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан килештерелгәннән соң, өч эш көне эчендә карап тикшерү өчен Башкарма комитетның хокук идарәсенә җибәрелә.

Килешүне килештерү турында карар проекты норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Башкарма комитетның Хокук идарәсе кимчелекләрне билгели һәм аларны төзәтү өчен, Башкарма комитетның тармак органы белгеченә җибәрә.

12. Башкарма комитетның Хокук идарәсеннән килешүне килештерү турында карар проекты кергән көнне Башкарма комитетның тармак органы белгече:

1) килешүне килештерү турында карар проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә;

2) килешүне килештерү турында карар проектына карата Башкарма комитетның Хокук идарәсе билгеләгән кимчелекләрне бетерә һәм, аларны килештерү өчен, Башкарма комитетның хокук идарәсенә җибәрә.

13. Башкарма комитетның тармак органы белгече Башкарма комитетның Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән килешүне килештерү турында карар проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

14. Башкарма комитет Җитәкчесе килешүне килештерү турында карар проектын яки килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын алар кергән көнне имзалый һәм, теркәү өчен, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

15. Муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе андый килешүне килештерү турында карар нигезендә төзелгән килешү буенча кабул ителгән йөкләмәләр үтәлгәннән соң, Башкарма комитетның тармак органы адресына, кабул ителгән йөкләмәләрнең үтәлеше турында хисап чорына бухгалтерлык балансын (ел, агымдагы елның 6 ае, агымдагы ел кварталы) һәм аңлатма язуын теркәп җибәрә.

16. Башкарма комитетның тармак органы, әлеге тәртипнең 15 пунктында каралган документлар кергән көннән башлап өч эш көне эчендә Башкарма комитет Җитәкчесе адресына муниципаль унитар предприятие, муниципаль

казна предприятиесе тарафыннан килешү буенча йөкләмәләр үтәлешенең барышы турында мәгълүмат җибәрә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева